# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керүе тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керүе тәртибе турында" 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы законнары, әгәр күрсәтелгән актларда аларның үз көченә керүенең башка тәртибе билгеләнмәсә, "Республика Татарстан" һәм "Ватаным Татарстан" газеталарында рәсми басылып чыккан көненнән Татарстан Республикасының барлык территориясендә бер үк вакытта үз көчләренә керә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актлары, әгәр күрсәтелгән актларда аларның үз көченә керүенең башка тәртибе билгеләнмәсә, кабул ителгән көненнән үз көчләренә керә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 30 июне
№ 34-ТРЗ